| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**27.10.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2964** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында» 2021 елның 30 декабрендәге 3440 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансланган кайнар ризык белән тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елның 12 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясенең чик күләмнәре турында» 2021 елның 30 декабрендәге 3440 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә

1нче пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«-Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган гомуми белем оешмаларының өлкән сыйныфлары өчен ирекле сайлау менюсы, бәясе 55,00 сум, шулардан 46 сум 70 тиен - ата-аналар түләве, 8 сум 30 тиен - субсидия».

2. 2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 12 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин